ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«05» декабрь 2024 ел № 949

**2025 елга Арча муниципаль районы коммуналь комплексы оешмалары тарафыннан халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясы, «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифларны расларга:

– торактан файдаланган өчен түләү (аренда өчен түләү), социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торагын наем шартнамәләре буенча арендалаучылар өчен торакны карап тоткан (алга таба – халыкка торак хезмәтләре күрсәтү) өчен, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак биналарның хуҗалары һәм 2025 елга торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында гомуми җыелышта карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак биналарның хуҗалары өчен түләү күләмен 1 нче кушымта нигезендә;

- муниципаль торак фондының торагын арендалаучылар өчен торактан файдаланган өчен тарифларны (аренда өчен база ставкасы) 2 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны «Татмедиа» ААҖ филиалы «Арча хәбәрләре» («Арский вестник») газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталына (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.М.Гатиятов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИНН 1609009516

*Арча муниципаль районы*
*Башкарма комитетының*
*«05» 12 2024 ел, № 949*
*карарына 1 нче кушымта*

**2025 елга торактан файдаланган өчен түләү (аренда өчен түләү), социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торагын наем шартнамәләре буенча арендалаучылар өчен торакны карап тоткан (алга таба – халыкка торак хезмәтләре күрсәтү) өчен, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак биналарның хуҗалары һәм 2025 елга торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында гомуми җыелышта карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак биналарның хуҗалары өчен түләү күләме**

| № | Түләү исеме | Түләү алына торган үлчәү берәмлеге | 2025 елның I яртыеллыгына хезмәт күрсәтүнең үлчәү берәмлеге өчен тариф (сум) | 2025 елның II яртыеллыгына хезмәт күрсәтүнең үлчәү берәмлеге өчен тариф (сум) |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Торак фонды белән идарә итү | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 5,20 | 5,20 |
| 2. | Ишегалдын карап тоту (шул исәптән чүп контейнерларын) | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 6,30 | 6,30 |
| 3. | Йорт эчендәге гомуми файдаланудагы урыннарны җыештыру | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 2,61 | 2,80 |
| 4. | Торак биналарга агымдагы ремонт ясау | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 4,10 | 4,30 |
| 5. | Дератизация (дезинсекция) | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 0,33 | 0,43 |
| 6. | Йорт эчендәге газ белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 0,30 | 0,32 |
| 7. | Йорт эчендәге электр челтәрләренә агымдагы ремонт | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 0,58 | 0,67 |
| 8. | Йорт эчендәге санитар-техник челтәрләргә (югары насос станцияләре белән җиһазландырылмаган су белән тәэмин итү һәм канализация | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 1,80 | 1,90 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 9. | Йорт эчендәге санитар-техник челтәрләргә (югары насос станцияләре белән җиһазландырылган су белән тәэмин итү һәм канализация челтәрләре) агымдагы ремонт | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 2,82 | 3,00 |
| 10. | Домофон | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 1,05 | 1,10 |
| 11. | Төтен юлларына техник хезмәт күрсәтү | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 1,00 | 1,10 |
| 12. | Җилләтү юлларына техник хезмәт күрсәтү | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 1,00 | 1,10 |
| 13. | Телевидениене күмәк кабул итү системаларын техник яктан тәэмин итү һәм ремонтлау | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 0,43 | 0,43 |
| 14. | Сыек кенкүреш калдыклары | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 13,00 | 13,00 |

Башкарма комитетның инфраструктура
үсеше бүлегенең ТКХ, энергетика
һәм элемтә секторы мөдире Э.Ф.Әхмәдиева

*Арча муниципаль районы*
*башкарма комитетының*
*«05» 12 2024 ел, № 949*
*карарына 2 нче кушымта*

**Муниципаль торак фонды торагын наем шартнамәләре буенча яллаучыларга тороктан файдаланган өчен (наем өчен) БАЗА СТАВКАСЫ**

| Түләү исеме | Хезмәт күрсәтүнең үлчәү берәмлеге | 2025 елга хезмәт күрсәтүнең үлчәү берәмлеге өчен тариф (сум) |
|---|---|---|
| Наем өчен база ставкасы | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 20 декабрендәге 1140 номерлы карары белән расланган торак урыннан файдаланган өчен түләү (наемга түләү), муниципаль торак фондының торак урыннарын социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча яллаучылар өчен түләү күләмен исәпләү методикасы нигезендә |

Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлегенең ТКХ, энергетика һәм элемтә секторы мөдире Э.Ф.Әхмәдиева